Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Кәркәүч авыл җирлеге Советы

КАРАР

«06» апрель 2026 ел №8

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 43 номерлы карары (2015 елның 15 июнендәге 27 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 14 номерлы , 2023 елның 22 сентябрендәге 17 номерлы үзгәрешләр белән);

«Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү турында һәм Кәркәүч авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Советының 2021 елның 07 июлендәге 18 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кәркәүч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кәркәүч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру тәртибен раслау һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибен раслау хакында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Советының 2022 елның 28 апрелендәге 10 номерлы карары;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы: М.Ф.Зәйнетдинов